| | |
|---|---|
| АЛЕКСЕЕВСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

11.11.2025 — № 15

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставы нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар итте:**

1. Муниципаль милектәге һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу турында Алексеевск шәһәр җирлеге тәкъдимен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына кабул итәргә.

2. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитеты белән типовой формага нигезләнеп килешү төзергә (Кушымта);

- әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатында 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Алексеевск муниципаль районы бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында Алексеевск муниципаль районы Советы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Килешүне гамәлгә ашыру өчен үз компетенциясе чикләрендә норматив һәм норматив булмаган хокукый актлар кабул итәргә хокуклы дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында хокукый акт текстын урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.А. Демидов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Советының
11.11.2025 № 15
карарына кушымта

Килешү
Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының муниципаль милектәге һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү һәм Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында

штп Алексеевск ____________________

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты, Устав нигезендә эш итүче җитәкчесе Свистунов Игорь Константинович йөзендә, алга таба «Җирлек башкарма комитеты» дип аталучы, бер яктан, һәм Нигезләмә нигезендә эш итүче җитәкчесе Леденцов Олег Николаевич йөзендә, алга таба «Район Башкарма комитеты» дип аталучы, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучы, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

1. Килешү Предметы

Әлеге Килешүнең предметы - җирлек башкарма комитеты тарафыннан муниципаль милектәге һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен һәм күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу өчен Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә муниципаль район бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә тиешле җирлекләр бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән тапшыру.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Җирлек Башкарма комитеты район Башкарма комитетына бирә:
- шушы Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары һәм матди ресурслар (алга таба-вәкаләтләр);
- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны.
2.2. Җирлек Башкарма комитеты хокуклы:
-район Башкарма комитеты вәкаләтләренең үтәлешен, шулай ук бирелгән финанс чараларының һәм матди ресурсларның максатчан файдаланылуын шушы Килешүнең 5.1-5.2 пунктларында билгеләнгән тәртиптә тикшереп торырга;

- район Башкарма комитетыннан әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүмат алырга.

2.3. Район Башкарма комитеты бурычлы:

- вәкаләтләрне законнар таләпләре нигезендә гамәлгә ашырырга, шул исәптән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга гына бирелгән финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

- җирлек Башкарма комитетына вәкаләтләр үтәлеше турында хисап, шулай ук аерым сораулар буенча Килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат тапшырырга.

2.4. Район Башкарма комитеты хокуклы:

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек Башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын һәм матди ресурсларны алырга һәм кулланырга;

- җирлек Башкарма комитетыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат соратып алырга;

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен законнар нигезендә өстәмә рәвештә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдаланырга.

## 3.Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджет законнары нигезендә бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары күләме Алексеевск муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты турындагы карары белән билгеләнә.

Яклар ел саен тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен әлеге килешүгә кушымта нигезендә билгели.

3.3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары квартал саен тигез өлешләр белән күчерелә.

3.4. Район Башкарма комитеты финанс средстволарын максатчан файдаланмаган очракта, алар ун көн эчендә район бюджетына кайтарылырга тиеш.

## 4.Матди ресурсларны тапшыру тәртибе

4.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен район Башкарма комитеты «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 10 өлешенең 5 пункты нигезендә әлеге Килешүгә кул куелган көннән алып утыз көн эчендә муниципаль мөлкәтне түләүсез срокլы файдалану шартнамәсе нигезендә кабул итә, ә җирлек Башкарма комитеты тапшыра.

4.2. Шушы килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән түләүсез файдалану шартнамәсе вакытлыча була һәм шушы Килешүнең гамәлдә булу срогына төзелә.

4.3. Шушы Килешүнең 4.1 пункты нигезендә тапшырылган матди ресурслардан файдалану тәртибе түләүсез файдалану шартнамәсе белән билгеләнә һәм аның мөһим шарты булып тора.

## 5.Вәкаләтләр үтәлешен тикшереп тору

5.1. Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүматны Башкарма комитеттан соратып ала. Район Башкарма комитеты җирлек Башкарма комитеты соравы буенча сорала торган мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керүен тәэмин итәргә тиеш.

5.2. Хисапларның рәвеше һәм аларны бирү тәртибе район Советының хокукый актлары белән билгеләнә.

## 6. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

6.1. Әлеге Килешү бер календарь елга төзелгән, ул яклар тарафыннан имзаланган вакыттан үз көченә керә һәм 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

6.2. Әлеге Килешү, әгәр якларның берсе дә аны өзү турында Килешүнең 6.1 пунктында каралган срок тәмамланырга ике ай кала хәбәр итмәсә, бер календарь елга озайтылган дип санала. Пролонгацияләр саны чикләнмәгән.

## 7. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе

7.1. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- якларның Килешүе буенча;
- Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта берьяклы тәртиптә.

7.2. Әлеге Килешүне өзү турында хәбәрнамә аның гамәлдә булу вакыты тәмамлану датасына кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча икенче Якка язма рәвештә җибәрелә.

7.3. Әлеге Килешү вакытыннан алда туктатылган очракта, район Башкарма комитеты җирлек Башкарма комитетына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс средстволарын һәм матди ресурсларны кире кайтара.

## 8. Яклар җаваплылыгы

8.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык башлануга нигез булырга мөмкин.

8.2. Бер Якның әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгәне өчен гаепле Як икенче Якка шушы Килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

8.3. Штраф түләү якларны әлеге Килешү буенча бурычларын үтәүдән азат итми.

## 9. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр яисә килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

## 10. Йомгаклау нигезләмәләре

10.1. Килешүгә барлык үзгәреш һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы белән кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

10.2. Килешү тигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә, һәр Як өчен берәр нөсхәдә төзелде.

## 11. Яклар имзасы

ТР Алексеевск муниципаль районы
Алексеевск шәһәр җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.К.Свистунов

ТР Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе О.Н.Леденцов

Килешүгә кушымта

______________

Раслыйм
Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге Башлыгы
___________ С.А.Демидов

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләре буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме

| N т/б | Чыгым статьясы | Сумма (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | Муниципаль милектәге һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү һәм норматив-хокукый җайга салуны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетыннан Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырыла торган вәкаләтләрне Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә тиешле җирлекләр бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән тапшыру | 1 |
| Гомум | | 1 (Бер) сум |